

Жылылык челтәрләре – һәрбер шәһәрнен зур коммуналь хужалыгынын моһим звеносы. Кvп фатирлы йортларда яшәv сыйфаты, жылылык энергиясе житештерv жайга салынуга бәйле. Монын очен предприятие челтәрләрен экс- плуатацияләv чорында тәvлек буе казаннар эшен контрольдә тотучы приборлар параметрларын кvзәтәләр, ә жәй коне аларны планлы ремонтлыйлар һәм жайга салу буенча торле хезмәт кvрсәтәләр. Югыйсә, аварияләр һәм жылылык югалтулары котылгысыз булачак.
Саранск буенча узган ягу сезонында торле аварияләр булды. Мәсәлән, Химмашта кайнар су трубалары эштән чыгу сәбәпле, йортларда халык жылысыз калган иде. Ә Темниково шәһәрендә киресенчә: «Узган ягып жылыту сезонын без vзәк котельныйнын эшен туктатмыйча vткәрдек, - дип сойли предприятие директоры Д.И.Пеняшкин. - Темниклылар бер сәгатькә дә кыйммәтле жылысыз калмады. Чонки салкын һәм унайсыз булса - шунда ук проблема, ә барысы да әйбәт булганда, димәк, шулай булырга тиеш. Алга таба да шулай дәвам итсен очен, без «чаналарны жәен әзерлибез», ягъни планлы ремонтка керештек. - Елдан-ел магистраль һәм бvлv торбаларыннан, приборлар һәм котельный станцияләреннән торган хужалык биредә идеаль тәртиптә тора. Узган ел моны безнен республикабыз Хокvмәте Рәисе - Председатель Правительства В.Ф.Сушков та районга рәсми визиты вакытында билгеләп vтте. Предприятиегә ул Мордовия торак-коммуналь хужалык министры И.А.Чадов белән бергә инспекция белән булды. Хәзер Гагарин урамындагы челтәрләрне ремонтлыйбыз, - дип дәвам итә Дмитрий Иванович. - Бу - ин зур магистраль жаваплыларнын берсе».
Жир астындагы торбаларны алыштыру турында сойләргә генә жинел. Чынлыкта исә, экскаваторчы жылылык трассасы vткән траншеяны казый, слесарьлар торбалар жәелгән тимер-бетон лотокны ача, эретеп ябыштыручы системанын «ышанычсыз» участогын кисә. Барлык эшләрне дә инженер хезмәте контроле астында эшләнә, ул соныннан житәкчеләргә башкарылган эшләрнен сыйфаты очен жавап бирә.
Алдагы эш планнарына килгәндә, челтәрләрне опрессовкалау әле тәмам- ланмаган. Жылыту сезоны нәтижәле булыр; салкыннар башлану белән фатирларында жылы һәм унайлы шартлар тудырылыр. Саранск жылылык инфраструктурасын ремонтлау һәм ре- конструкцияләv эшләрен дәвам итә. 2020 елда барлык тобәкләрдә 423 километр жылылык челтәрен алыштырырга планлаштыра, ди ви- деоэлемтә буенча матбугат конференциясе барышында «Т Плюс» генераль директоры Андрей Вагнер. - Бу кvрсәткеч узган еллардагыга караганда берничә тапкыр кvбрәк булмаса да, һәр километр моһим», - дип билгеләп vтте ул.- Узган ел белән чагыштырганда, жылылык чел- тәрләрен ремонтлау һәм реконструкцияләvгә чыгымнар 22%ка артачак. Бу максатларга

15 млрд. сумнан артык акча каралган. Якынча шундый ук кvләмдә инвестицияләр генерациягә биреләчәк.
Мордовиядә жылыту сезонына әзерлек очен 780 млн сум акча тотылачак, дип сойләде «Т Плюс» жәмгыятьчелегенен Мордовия филиалы директоры Андрей Ванин. «Өлеге ремонт кампаниясе очен материаллар сатып алынган. Барлык эш торләренә дә подрядчылар табылган, - дип хәбәр итте Андрей Ванин.- Быел Саранскта 18 километр жылылык һәм кайнар су белән тәэмин итv челтәрләре сузылачак. Севастопольская урамында юл астында жәелгән инде. Анда эшләрнен калган олеше планлы рәвештә кайнар суны туктатып тору вакытында башкарылачак. Жылылык челтәрләреннән тыш, генерацияләv жайланмаларын да тәр- типкә китерергә кирәк. Ике градирны ремонтлау очен генә дә 70 млн. сумга якын акча тотылачак. Шулай ук котельналарга ремонт ясалачак, станциядә эшләр, бер турбина һәм ике энергетика казаннары реконструкцияләнәчәк».
Шуна да кышын - арба, жәен - чана әзерлибез.

**Наилә НАСЫРОВА**